СОВЕТ
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабрь 2018 ел г.Мензелинск № 7

**2019 елга халыкка күрсәтеләчәк**
**торак-коммуналь хезмәтләргә тарифлар турында**

2004 елның 30 декабрендә кабул ителгән “Коммуналь комплекс оешмаларының тарифларын җайга салу нигезләре турында”гы №210-ФЗ Федераль законы, Россия Федерациясенең Торак кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августында кабул ителгән “Хезмәтләр күрсәткәндә һәм идарә, күпфатирлы йортта гомуми милекне тәртиптә тоту һәм ремонтлау буенча эшне билгеләнгән вакыттан озаграк, өзеклек белән башкарган очракта, күпкатлы йортта гомуми милекне тәртиптә тоту һәм торак бинаны тәртиптә тоту һәм ремонтлау өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында”гы №491, Татарстан Республикасы Президентының 2018 елның 14 декабрендә кабул ителгән “2019-2023 елларга Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнардан кергән түләүләр күләменең чикләнгән (максималь) үзгәреш индексы күләме турында”гы №210-ФЗ Карары, Татарстан Республикасының Министрлар Кабинетының 29.06.2013 елда кабул итлегән “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми милеккә капиталь ремонтка взносның минималь күләмен билгеләү турында”гы №450 карарына үзгәрешләр кертү турында”гы карарлар нигезендә

МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ КАРАР ЧЫГАРА:

1. Расларга һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 31 декабренә кадәр гамәлгә кертергә:

күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулы турында карар кабул итмәгән торак бина хуҗалары һәм муниципаль торак фондының торак биналарына социаль наем һәм наем килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар һәм торак бинаны тәртиптә тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак биналар хуҗаларына календарьне 1 нче кушымта нигезендә 2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә

кадәр, 2019 елның 1 июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр бүлеп түләү күләме;

2 нче кушымта нигезендә, муниципаль торак фондының торак биналарын наемга алу килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар өчен (наем өчен база ставкасы) торак бинадан кулланган өчен база ставкасы;

3 нче кушымта нигезендә, торак бина хуҗалары өчен капиталь ремонтка түләү;

2. Гамәлдәге карарны "Минзәлә" – "Мензеля" район газетасында бастырырга.

3. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисад, бюджет һәм эшмәкәрлек буенча комиссия рәисе Р.Ш.Газизяновка, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты Җитәкчесе К.Р.Нәҗмиевка, Минзәлә муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше һәм инвестицияләр буенча урынбасары Д.А.Чухланцевка йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы А.Ф.Салахов

Кушымта № 1
Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль район
Советы карарына
дата 25.12.2018 ел. № 7

**Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулы турында карар кабул итмәгән торак бина хуҗалары һәм муниципаль торак фондының торак биналарына социаль наем һәм наем килешүләре буенча торак биналарны наемга алучылар һәм торак бинаны тәртиптә тоткан һәм ремонтлаган өчен түләү күләмен билгеләү турында гомуми җыелышта карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы торак биналар хуҗаларына түләү күләме**

| Тәртип № | Түләү атамасы | Хезмәтнең үлчәү берәмлеге | Хезмәткә үлчәү берәмлеге өчен тариф (сумнарда), НДСны исәпкә алып | |
|---|---|---|---|---|
| | | | **2019 елның 1 гыйнварыннан 2019 елның 30 июненә кадәр .** | **2019 елның 1 июленнән 2019 елның 31 декабренә кадәр.** |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 2,26 | 2,26 |
| 2 | Йорт яны территориясен җыештыру | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 2,42 | 2,43 |
| 3 | Торак биналарны ремонтлау һәм йорт яны территорияләрен тәртипкә китерү | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 2,81 | 2,82 |
| 4 | Йорт эчендәге инженерлык суүткәргеч-канализация челтәрләренә ремонт һәм техник хезмәт күрсәтү | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 1,89 | 1,93 |
| 5 | Йорт эчендәге җылылык челтәрләренә ремонт һәм техник карау уздыру | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының | 0 | 0 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | кв. метры | | |
| 6 | Газ белән тәэмин итү челтәрләренә техник карау уздыру | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 0,3 | 0,31 |

| | | |
|---|---|---|
| Капиталь ремонт | бер айга торак бинаның гомуми мәйданының кв. метры | 5,85 |

Минзәлә муниципаль район
Башлыгы
-

А.Ф.Салахов